# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында**
**дәүләти-хосусый партнерлык турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы катнашында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру максатларын, бурычларын, принципларын, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләрен билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) дәүләти-хосусый партнерлык – дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү һәм үтәү юлы белән, шул исәптән муниципаль берәмлекләр катнашында, социаль әһәмияткә ия инфраструктура, инновация, инвестиция проектларын һәм башка проектларны, программаларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы һәм хосусый партнерлар арасында үзара файдалы хезмәттәшлек;

2) дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү (алга таба шулай ук – килешү) – дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары арасында төзелә һәм дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашырганда аларның хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын билгели торган шартнамә;

3) килешү объекты – интеллектуаль милек, килешү нигезендә булдырыла, реконструкцияләнә, эксплуатацияләнә торган мөлкәт;

4) килешү объектын булдыру – килешүнең әлегә кадәр булмаган объектын булдыру, шул исәптән яңа технологияләр, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру нигезендә дә, килешү объектында яңа җитештерү җайланмасы урнаштыру, килешү объектын булдыруны һәм аның эшләвен тәэмин итүче бүтән төрле эшләр башкару;

5) килешү объектын реконструкцияләү – яңа технологияләр кертү, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру, әхлакый яктан искергән һәм физик яктан тузган җайланманы модернизацияләү һәм җитештерүчәнлеге югарырак булган җайланмага алмаштыру нигезендә үзгәртеп кору, шулай ук килешү объектының яисә аның аерым өлешләренең технологик яисә функциональ билгеләнешен үзгәртү чаралары, килешү объектының характеристикаларын һәм эксплуатацияләү үзенчәлекләрен яхшырту буенча башка чаралар;

6) килешү объектын эксплуатацияләү – хосусый партнерның килешү объектыннан аның билгеләнеше нигезендә, шул исәптән килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда товарлар җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү максатларында файдалануы.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләрнең һәм терминнарның бу статьяда ачыкланмаганнары федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның максатлары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның максатлары, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларыннан файдаланып, ә килешү муниципаль берәмлекләр катнашында төзелгән очракта – шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджеты акчаларыннан һәм (яисә) муниципаль милек объектларыннан файдаланып, Татарстан Республикасында социаль әһәмияткә ия, шул исәптән инфраструктура, инновация, инвестиция проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыру өчен матди, финанс ресурсларны туплаудан, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклар акчаларын җәлеп итүдән гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) инновацияле икътисадны үстерү, матди-техник базаны техник һәм технологик яктан үстерү, яңарту, шулай ук икътисадта фәнни куәтле, югары технологияле тармакларның чагыштырма күләмен арттыру;

2) Татарстан Республикасы икътисадына хосусый инвестицияләр җәлеп итү;

3) дәүләт мөлкәтен, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан, ә килешү муниципаль берәмлекләр катнашында төзелгән очракта – шулай ук

муниципаль мөлкәтне һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру;

4) социаль, транспорт һәм инженерлык инфраструктуралары объектларыннан файдаланып, халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеген арттыру һәм аларның сыйфатын яхшырту;

5) халыкның эш белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен арттыру.

4 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру принциплары**

Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык түбәндәге принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) килешү якларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

2) килешү якларының намуслы һәм үзара файдалы хезмәттәшлеге;

3) дәүләти-хосусый партнерлыкның нәтиҗәлелеге;

4) килешү якларының матди, финанс, интеллектуаль, фәнни-техник ресурсларын берләштерү;

5) килешү яклары арасында җаваплылыкны, ихтимал хәвефлелекне һәм ирешелгән нәтиҗәләрне бүлешү;

6) килешү яклары эшчәнлегенең ачыктан-ачык булуы;

7) килешү якларының йөкләмәләрне һәм аларны үтәү бурычын үзләре теләп алуы.

5 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән башкарма органы (алга таба – вәкаләтле орган) аша Татарстан Республикасы, бер яктан, һәм хосусый партнер, икенче яктан, дәүләти-хосусый партнерлыкның субъектлары (килешү яклары) булалар.

2. Россиянең юридик яисә физик заты йә юридик зат төземичә генә гади ширкәт шартнамәсе (уртак эшчәнлек хакында шартнамә) буенча эш итүче, эшчәнлеген килешү нигезендә башкаручы юридик затлар берләшмәсе хосусый партнер була ала.

Чит илнең юридик яисә физик заты да, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, хосусый партнер була ала.

3. Әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән затлар белән беррәттән, тиешле җирле үзидарә органнары аша ихтыярый башлангычларда муниципаль берәмлекләр дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары (килешү яклары) булырга мөмкин.

**6 статья. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы финанс, мөлкәт рәвешләрендә, мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә һәм законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта финанс рәвешендә катнашуы субсидияләр, бюджет инвестицияләре, хосусый партнерларның йөкләмәләре буенча дәүләт гарантияләре, инвестицияле салым кредиты, килешүләрдә каралган чараларны финанслау яисә финанслашу юлы белән һәм законнарда тыелмаган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мөлкәт рәвешендә катнашуы хосусый партнерга җир турындагы законнар нигезендә җир кишәрлекләре бирү, хосусый партнерга шартнамә нигезендә башка күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәт тапшыру юлы белән, законнарда тыелмаган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта мәгълүмати ярдәм күрсәтү рәвешендә катнашуы региональ мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре төзү һәм аларның эшләвен тәэмин итү юлы белән, шулай ук законнарда тыелмаган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Бер килешү кысаларында Татарстан Республикасы дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның бер яисә берничә рәвешендә катнаширга мөмкин.

6. Дәүләти-хосусый партнерлык мөнәсәбәтләрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең катнашу рәвешләре, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

**7 статья. Дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзү**

1. Законнарда каралган очракларда килешү законнарда билгеләнгән тәртиптә сәүдәләр үткәрү йомгаклары буенча төзелә.

2. Сәүдәләр үткәрү йомгаклары буенча килешү төзү законнарда каралмаган очракларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты килешү төзү турында карар кабул итә, анда түбәндәгеләр раслана:

1) килешү шартлары, шул исәптән килешү объектының составы һәм тасвирламасы;

2) Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвеше;

3) вәкаләтле орган;

4) килешү төзү ысулы (сәүдәләр үткәргәндә яисә сәүдәләр үткәрмәгәндә килешү төзү);

5) конкурс документациясе составы һәм эчтәлеге, килешү сәүдәләр үткәргәндә төзелгән очракта – конкурс комиссиясе составы;

6) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләмәләр.

3. Килешү төзү турында карарны ул кабул ителгәнчегә кадәр, әлеге статьяның 2 өлешендәге 1, 2 һәм 4 пунктларында каралган шартлар өлешендә, Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык буенча киңәшү органы белән килештерү мәҗбүри.

4. Килешү төзү турында кабул ителгән карар хакындагы хәбәр Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Сәүдәләр үткәрмичә генә килешү төзегәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә вәкаләтле орган килешү төзү турындагы карар нигезендә, Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруның әлеге Законда билгеләнгән принципларын исәпкә алып, потенциаль хосусый партнерлар белән килешү шартларын килештерүне тәэмин итә.

## 8 статья. **Хосусый партнерның килешүне үтәвен тикшереп тору**

1. Хосусый партнерның килешүне үтәвен тикшереп тору вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Хосусый партнерның килешүне үтәвен вәкаләтле орган тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе килешү белән билгеләнә.

## 9 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итү**

1. Төзелгән килешүләр турында мәгълүмат, дәүләти-хосусый партнерлыкта Татарстан Республикасының катнашу рәвеше турында, килешү шартлары һәм объекты хакында, килешүгә үзгәрешләр кертү, аны өзү һәм үтәү турында белешмәләрне кертеп, Дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләр реестрына (алга таба - Реестр) кертелә.

2. Реестрны булдыру һәм алып бару тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Реестрны булдыруга һәм алып баруга вәкаләтле органы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

3. Реестрдагы белешмәләр Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында урнаштырыла һәм һәр квартал саен яңартыла.

10 статья. **Килешүләр төзегәндә һәм аларны үтәгәндә хосусый партнерның хокуклары гарантияләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, аларның вәкаләтле затларының законсыз гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында хосусый партнерга зыян килгән очракта, килгән зыяннарны ул граждан законнары нигезендә түләтүне таләп итәргә хокуклы.

2. Хосусый партнер, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, түбәндәге хәлләр барлыккка килгән очракта килешүгә хосусый партнер таләбе буенча аның шартларын үзгәртүне күздә тотучы нигезләмәләр кертүне таләп итәргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасының килешү буенча нинди дә булса йөкләмәне бозуы яисә тиешенчә үтәмәве;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы яисә бу органның вәкаләтле заты тарафыннан хосусый партнерның килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәвенә каршы килә торган, партнерның хуҗалык эшчәнлегенә нигезсез тыкшынуны да кертеп, карар кабул итү яисә гамәлләр кылу;

3) килешү гамәлдә булган чорда хосусый партнерның хәлен начарайта торган, шул исәптән аңа килешү төзегән вакытта гамәлдә булган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән чагыштырганда аңа өстәмә йөкләмәләр йөкли торган Татарстан Республикасы норматив хокукый акты кабул итү;

4) конкурс документациясендә күрсәтелгән белешмәләрнең факттагы белешмәләргә туры килмәвен билгеләү, шулай ук анда хосусый партнерның килешү буенча йөкләмәләрен үтәүгә каршы килүче башка хаталарны яисә төгәлсезлекләр булуын ачыклау;

5) хосусый партнерга бирелгән мөлкәтнең килешү төзегәндә хосусый партнерга билгеле булмаган һәм билгеле була да алмаган йөкләмәләре булуны ачыклау;

6) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка очракларда.

3. Килешү объектларын булдыруны, реконструкцияләүне, эксплуатацияләүне финанслауда Татарстан Республикасының катнашу күләмнәре һәм сроклары федераль законнарда һәм килешүдә каралган очракларда билгеләнгән тәртиптә үзгәрергә мөмкин.

11 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык буенча киңәшү органы**

1. Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен эшләгәндә, дәүләти-хосусый партнерлык субъектлары мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү, килешүләрне гамәлгә ашыру мониторингын башкару һәм Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка бурычларны хәл итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык буенча киңәшү органы (алга таба – киңәшү органы) төзелә.

2. Әлеге Законның 5 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән затлар вәкилләре саны киңәшү органы әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесен тәшкил итәргә тиеш.

3. Киңәшү органының шәхси составы һәм эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

12 статья. **Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуына бәйле чыгымнарны финанслау**

Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуына бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм законнарда тыелмаган башка чыганаклардан гамәлгә ашырыла.

13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 50-ТРЗ